**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

28.06.2021 г. Казань № 67од

Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары аппаратларында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенә керү турында

«Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җәмәгать судьялары турында» 1998 елның 17 декабрендәге 188-ФЗ номерлы Федераль законның 7 һәм 9 статьялары, «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» 1999 елның 17 ноябрендәге 2440 номерлы Татарстан Республикасы Законының законның 7 һәм 9 статьялары нигезендә, боерам:

1. Гражданинның Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары аппаратларында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте (алга таба – граждан хезмәте) вазыйфасына билгеләнүе яки дәүләт граждан хезмәткәренең җәмәгать судьясы аппаратында граждан хезмәтенең тиешле вазыйфага вәкаләтләр вакытын чикләмичә билгеләнгән (сайланган) башка вазыйфасын биләп торуы конкурс нәтиҗәләре буенча яки кадрлар резервыннан башкарыла дип билгеләргә.

2. Конкурс үткәрелми дип билгеләргә:

граждан хезмәтенең кече вазыйфалары төркеменә караган граждан хезмәте вазыйфасына билгеләнгәндә;

граждан хезмәтенең өлкән вазыйфалары төркеменә караган граждан хезмәте вазыйфасына билгеләнгәндә, тиешле суд участогы җәмәгать судьясы вәкаләтләре вакытына хезмәт контрактын төзү белән.

3. Татарстан Республикасы юстиция министрының «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары аппаратларында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре белән төзелә торган хезмәт контрактлары турында» 2020 елның 27 апрелендәге 55од номерлы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз карамагымда калдырам.

Министр Р. И. Заһидуллин